**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"09" ноябрь 2022 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чишмәле Сап торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 2023 елда Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1нче төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Чишмәле Сап авылында урам юлларын төзекләндерүгә вак таш алу;
2) Чишмәле Сап авылы территориясен чистарту, агачлар һәм куакларны кисү;

3. 2021, 2022 еллардагы экономияләнгән үзара салым акчасын, Чишмәле Сап авылында урам юлларын төзекләндерүгә вак таш алуга юнәлтергә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чишмәле Сап авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Яңа Шашы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

5. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чишмәле Сап авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.